
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



**Язның беренче бәйрәме котлы булсын!**

№7
Март 2026 г.




Мәктәп үзидарәсе укучылары барлык хатын-кыз укытучылар, хезмәткәрләрне һәм укучы кызларны 8 март бәйрәме белән чын күңелдән котлый!

Сезгә профессиональлегегез, ярдәмегез, белем үстерүгә һәм үсәргә ярдәм итүче акыллы киңәшләрегез өчен рәхмәт белдерәбез. Сезнең җаваплылыгыгыз, көчегез һәм ышанычлылыгыгыз — үсеп килүче буын өчен үрнәк.

Ныклы сәламәтлек, иминлек, яңа казанышлар һәм барлык башлангычларда уңышлар телибез! Һәр көн шатлык, илһам һәм күңелле сюрпризлар китерсен!

**С прекрасным праздником 8 Марта!**

Ученики школьного самоуправления от всего сердца поздравляют всех работников - женщин нашей школы весенним праздником!Милые дамы, оставайтесь такими же лучезарными и очаровательными, истинными эталонами красоты и обаяния. Будьте счастливы и дома, и на работе, благополучия и семейного уюта вам, успеха во всех начинаниях. вам!

## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Әниләрнең җылы кочагы | 2 |
| Мәктәп яңалыклары | 3 |
| Школьные новости | 4 |
| Татар халкының мәкаль һәм әйтемнәре | 5 |
| Нәсел җебен барлаганда... | 6 |

# Әниләрнең жылы кочагы

### *Җәннәт әниләрнең аяк астында*

Әни, әнкәй, инәй... Кеше өчен алтын – көмешләрдән дә кыйммәтле, үз җанынннан да кадерле, барлык изгелекләрдән дә изге сүзләр - шушыдыр. Үз гомерендә адәм баласына бу сүзләрне ничәмә – ничә тапкыр кабатларга туры килә икән? Әмма күпме генә кабатламасын, әлеге сүзләрдән ул һич кенә дә туймый, киресенчә, еллар узган саен “әни” сүзенең тәмен ныграк тоеп яши . Күпме наз, күпме җан җылылыгы бу сүздә!

Әнкәйләр – безгә тормыш биргән гүзәл затлар. Һәр кеше өчен үз әнисе кадерле кеше булган кебек, миңа да үз әнием - кадерлеләрнең дә кадерлесе. Барлык балаларныкы кебек, минем дә телем “әннә” сүзе белән ачылган. Әнием мине күкрәк сөтен имезеп үстергән, көннәрен дә, төннәрен дә миңа - газизенә багышлаган. Әнием – минем җан юлдашым, терәгем, киңәшчем, яклаучым һәм таянычым. Аллаһы Тәгалә тарафыннан әти булу бәхетенә ирешеп, үз сабыйларымны кеше итәр, күңел түремә әнием салган тәрбия җимешләренең куанычын татыр көннәрем алда әле минем. Шул көннәрдә дә янәшәмдә әниемнең булуын, аның кытыршы кулларының җылысын тоясым , “балакаем” дигән татлы сүзен ишетәсем, “әнием – бәгырем” дип өзелеп торасым килә. Учларыма әнием кулын алып мин ниндидер изге эйбергә кагылган кебек булам: минем җаным яктырып китә, тормыш аңлаешлы һәм гади булып тоела башлый, борчулар һәм хәсрәтләр онытыла.

Янәшәмдә әнием булганга минем тормышым дәвам итә, киләчәгемнең яхшы һәм бәхетле булачагына ышанычым арта. Мин шуны яхшы аңлыйм: тормышта мин бәхетле икән, әнием дә чиксез бәхетле булачак, чөнки ана һәм баланы гомер азагына кадәр бәйләп торучы күзгә күренмәс җепләр бар. Шуның берсе генә кинәт өзелсә дә, бу ике кешенең яшәү мәгънәсе бетәчәк. Әниемне бәхетле итәр өчен кулдан килгән бөтен нәрсәне дә эшләргә ризамын, бары әниемнең күзләреннән шатлык чаткылары сүнмәсен дә, Ходай биргән гомерендә бала хәсрәте татырга язмасын иде.

**Адилә** Гыйләҗетдинова,
8 А сыйныфы

### *Әниемнең җылы кочагы*

Әни— кыска булуга карамастан, үзенә чиксез мәхәббәт яшергән сүз.

Әни—сине ничек бар шулай, бернинди кимчелекләрсез яратучы бердәнбер кеше. Аның яратуы синең холкыңа, укуыңа, сәламәтлегеңә карамастан чиксез. Томышыбызның беренче минутларыннан башлап, тынычлыгыбызны саклап, көнен-төнен кайгыртып яшәүчебез дә ул безнең. Үсеп буйга җиткәч тә әниебезнең киңәше, ярдәменә мохтаҗ без. Гаиләбезнең терәге, бизәге дә - ӘНИЛӘР!

**Камил** Сөнгатов,
4 Б сыйныфы.

*Көннәр якты булсын өчен,*
*Йокы татлы булсын өчен*
*Әни кирәк, әни кирәк.*
*Йокы татлы булсын өчен*
*Әни кирәк!*

*Җил-яңгырдан саклар өчен,*
*Усаллардан яклар өчен*
*Әни кирәк, әни кирәк.*
*Усаллардан яклар өчен*
*Әни кирәк!*



# Мәктәп яңалыклары

## Мәктәпнең горурлыгы!

13 мартта «Чын кеше тәрбияләү» конкурсының муниципаль этабы – үсеп килүче яшь буынны тәрбияләүдә үзләрен игелекле эшкә багышлаучылар өчен һөнәри ярыш булып узды. Конкурста районның барлык мәгариф учреждениеләреннән сыйныф җитәкчеләре, педагог-оештыручылар һәм тәрбия буенча директор киңәшчеләре катнашты. Бу чын педагогик осталык бәйрәме булды, анда катнашучылар үзләренең авторлык эшләнмәләре, инновацион методикалары белән уртаклаштылар.

Безнең мәктәпне 9Б сыйныф җитәкчесе Зарина Камалеева лаеклы тәкъдим итте.



18 нче март көнне Кырымның Россиягә кушылуына 12 ел тулу уңаеннан мәктәптә 1-11 сыйныфларда «Кырым һәм Россия – бердәм язмыш»тематик класс сәгатьләре узды. Укытучылар укучыларга Бу мөһим датаның илебез тарихындагы әһәмияте турында җентекләп сөйләделәр.

Дәрес укучыларга әлеге вакыйганың әһәмиятен аңларга ярдәм итте.




## Шигърият—ул күңел аһәңе!

Шигърият көне кысаларында безнең мәктәптә әдәби кунакханә узды. Балалар гүзәллек турында сөйләшергә, шигырьләр укырга һәм нәфис сүз белән ләззәтләнергә җыелдылар. Укучылар яраткан авторларының әсәрләрен укып, рифмалар һәм образлар дөньясына чумдылар. Насифуллина Эльвираның чыгышы кичәнең аеруча дулкынландыргыч мизгеле булды. Ул шигырьләрне генә укып калмады, үз иҗат иткән шигырьләрен тамашачыларга тәкъдим итеп, эчтәлеге белән уртаклашты. Эльвира, кыюлыгың, ихласлыгың һәм талантың өчен рәхмәт сиңа! Синең юлларыңда беркем дә битараф калмады. Сиңа киләчәктә дә иҗади уңышлар һәм яңа шигъри ачышлар телибез!





**Яз килә** (М.Мазунов)

Көннәр аяз, күктә алсу
Нур сибеп кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы –
Сагынып көткән яз
килә.Әйтегезче,кайсы вакыт
Яздагыдан ямьлерәк?
Кыш айларын да яратам,
Әмма яз күңеллерәк.Көннәр җылы,
күктә алсу
Нур сибеп кояш көлә,
Җәйге шатлык, көзге бәхет
Яз белән бергә килә.

# Школьные новости

### Балаларның иминлеге - безнең төп бурычыбыз



Мәктәптә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауга багышланган мөһим чаралар узды. 1-11 сыйныф укучылары өчен тематик класс сәгатьләре үткәрелде, аларның төп максаты — куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшерү генә түгел, ә балаларны стандарт булмаган һәм куркыныч ситуацияләрдә дөрес җавап бирергә өйрәтү.

Сыйныф җитәкчеләре белән бергә балалар фикер алыштылар:
Террорчылык нәрсә ул һәм ни өчен ул җәмгыять өчен куркыныч булып тора.
- Шикле әйберләр табылганда үзеңне ничек тотарга.
- Кулга алганда яки эвакуация вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре.
- Уяулыкның һәм үз гамәлләрең өчен җаваплылыкның мөһимлеге.

Без Толерантлык һәм бер-беребезгә хөрмәт тәрбияләүгә аерым игътибар бирдек, чөнки профилактика коллективта дустанә атмосферадан башлана.

### «Кырым белгечләре» викторинасы

19 нчы март көнне мәктәптә шунддый күңелле чара узды! 5-7 класс укучылары өчен Кырымга багышланган мавыктыргыч викторина булды. Балалар сорауларга җавап бирделәр: ярымутрау географиясе турында; әһәмиятле тарихи вакыйгалар; табигый истәлекле урыннарда булып мәдәни һәм архитектура һәйкәлләре белән таныштылар. Укучылар бик яхшы эрудицияле, көчле команда икәнлекләрен расладылар. Әлеге кичә алар өчен бик файдалы, мавыктыргыч булды. Һәр этапта катнашып, зур кызыксыну күрсәттеләр. Оештыручылар өчен дә укучылар истә калырлык бәйрәм булды бу көн.

### С достоинством представила район и школу!




Наш педагог-организатор Шамилова Алиса Ильгамовна приняла участие в зональном этапе республиканского конкурса профессионального мастерства работников сферы воспитания и дополнительного образования «Воспитать человека».

Алиса Ильгамовна выступила в номинации «Воспитательные траектории детских общественных организаций и объединений», где представила опыт работы нашего медиацентра.

Выступление было ярким, глубоким и очень искренним — именно так, как она работает с детьми каждый день. Наша участница достойно представила Арский район и школу на зональном этапе.

Гордимся нашим педагогом и ждём результатов! Какой бы ни была оценка жюри, мы уже знаем: Алиса Ильгамовна — настоящий профессионал и человек, который действительно воспитывает сердца.

# Татар халкының мәкаль һәм әйтемнәре

Борынгы әби-бабаларыбыз үзләре өчен генә яшәмәгәннәр. Балалары, оныклары өчен дә борчылганнар. Үзләре ясаган, аңлаган ялгышларда, балаларын әлеге хаталардан сакларга тырышканнар.

Без, мәкальләр барысы да тәрбия чарасы буларак алынган дип уйлыйбыз. Яхшы дуслар табарга, бер-береңә кисәтү ясарга, алган әйбереңне урынына куярга өйрәнергә, хаталану турында матур һәм җыйнак итеп әйтергә ярдәм итүләре белән файдалы мәкалҗләр бик күп.

Мисал өчен:

Дустың нинди, үзең шундый.

Кем арбасына утырсаң , шуның җырын җырлыйсың.

Бер тырмага ике басмыйлар.

Ерак куйсан – якыннан алырсың һ.б.

Мәкаль чикләвеккә охшаган: аның “кабыгы һәм “төше” бар. “Кабыгы”- турыдан туры әйтелгәне. Ә “төше”- аның яшерен мәгънәсе. Ул турыдан-туры әйтелми, “кабык” эченә яшеренә. Әлеге мәкальләрне аңлау өчен, ныклап уйлау зарур. Күп кенә мәкальләр турыдын-туры әйтелгән мәгънәне белдермиләр.

Әйтемнәрнең безгә билгеле ягы –кыска булуында. Ләкин кыскалык аның җитди ягы түгел. Телägән фикереңне , җитди, аңлаешлы итеп әйтергә мөмкинлек биргән әйтемнәр сөйләшкәндә кулланыла.

Мәкальләр халкыбызның тарихын да, язмышын да, акылын-фигылен, милли зәвыгын һәм башка сыйфатларын да чагылдыралар.

Мәкальләр кешенең ни эшләгәнен, ялгыш юлга басмадымы, яки нәрсә эшләргә белми аптырап калдымы, бу вакыйга янында шунда ук мәкаль сикереп төшкән. Шуңа да күп белүчегә зирәк кеше, диләр.Сөйләмебездә әйтем, мәкальләрнең тоткан урыны, әһәмияте бик зур. Ул сине башкалардан белемлелеген, сүзгә осталыгыңны күрсәтсә, әйтергә теләгән фикереңне туры яки күчерелмә мәгънәдә аңларга мөмкинлек бирә.

Проект эшен башкарганда, кеше язмышларының төрлечә булуына игътибар иттек. Кеше язмышларына ияреп аның теле, гореф – гадәтләре йөри иканен аңладык. Ләкин ничек кенә булмасын, һәркемнең җирдә үзе генә салган сукмагы, нәкъ ул гына ашыйсы ризыгы, “маңгаена язылган күрәчәге”, борчу – шатлыклары, сөенеч – кайгылары була. Киләчәккә ныклы адымнар белән бару өчен, үрнәк итеп алырдай шәхесләр, гасырлар буена сакланып килгән татар телебез, әдипләребез, ил тарихында калдырган эшләре, без – яшьләр өчен өлге итеп алырлык. Буыннарны башка буыннар алыштыра. Яңа буын кешеләре күңеленнән тарихның башка вакыйгалары үтә. Бу вакыйгалар, шулай ук күңелләрдә үз дөньяларын тудыралар. Ләкин татар теленең сүзлек хәзинәсе һәм тарихы искерми, ул тарихның бер чорыннан икенчесенә күчеп яңара, тулылана гына бара. Ә тел язмышы – ул милләт язмышы, аның яшәеше, үсеш формасы. Кешелек әледән – әле милләтнең таянычы булган, йөрәк пәрәсеә нечкә, кадерле башка тәр могҗизаны уйлап тапмаган, таба да алмас, бу бөек көчне бер нәрсә дә алыштыра алмый.

Мәкальләрнең иң кыска, бер-ике сүз белән ачык кына итеп күп мәгънә әйтә алучанлыклары бик зур язучыларны кызыксындыра килгән һәм язучылар үзләре дә шундый иппе, җыйнак, тапкыр, анык һәм шигъри тирән мәгънәле итеп әйтә-яза белә.




Сораштырулар, бүгенге көндә дә, тормышыбызда әһәмиятен югалтмаган мәкаль һәм әйтемнәребезне бик теләп файдаланылганы югарыдыгы нәтиҗәдә күренә.

**Искәндәр** Насыйбуллин,
**Ислам** Усманов, 8 А сыйныфы.

# Укучылар иҗаты

## Нәсел җебен барлаганда...

Нәсел шәҗәрәсе-ул ата-бабаларыбызның туганнары, аларның исемнәре, яшәү вакыты, тышкы һәм физик мәгълүматлары, социаль һәм милек хәле, шулай ук аларның яшәү урыннары, аларның биографияләре белән бәйле төп вакыйгалар турындагы белешмәләрнең документаль расланган җыелмасы.

Шул ук вакытта шуны истә тотарга кирәк: бу-туганлык, туганлыкка, милләткә карата мөнәсәбәт урнаштыру, ә туганнарның иң якты биографияләре булган гаилә тарихы. Мин үз гаиләмнең тарихын, ата-бабаларымның ничек яшәгәнен һәм нәрсә белән шөгыльләнгәнен белергә теләдем. Без туганнарым белән гаилә архивларын өйрәндек, китаплар һәм интернет ресурсларыннан мәгълүмат эзләдек.

Һәр кеше үз милләтенең тарихын, авыллары язмышын, нәсел-ыруы бәйләнешен, җиде буын әби-бабасын, аларның һөнәрләрен белергә тиеш. Бу – ерак гасырлардан тапшырылып килгән иң олы әманәтләрнең берсе. Соңгы елларда милләттәшләребездә олысы-кечесенең үз шәҗәрәләрен өйрәнә башлавы зур игътибарга лаек.

"Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк!",- ди татар халкы. Үз чиратымда, мин дә нәсел турында уйланырга, өлкәннәрдән сорашырга, төпченергә яратам. Бүгенге хезмәтем нәсел җебен барлау, андагы буыннар чылбырын табу турында. Танылган язучы Гариф Ахунов әнием ягыннан өченче буын туганыбыз булганга әлеге проектны башкардым.

"Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк!",- ди татар халкы. Үз чиратымда, мин дә нәсел турында уйланырга, өлкәннәрдән сорашырга, төпченергә яратам. Бүгенге хезмәтем нәсел җебен барлау, андагы буыннар чылбырын табу турында булыр. Өлкәннәр исән булганда, сөйләргә кеше булганда аны өйрәнергә, үткәнне искә төшерергә, киләчәк буыннарга да җиткерергә кирәк дип уйлыйм. Мин Арчада туып үссәм дә нәселебез Гөберчәк авылына барып тоташа. Мин бу авылны бик яратам. М.Мәһдиев музеенда булганым, Сафиулла бабай чишмәсенең суын эчкәнем, Ибәт наратына карап хозурланганым бар. Авылыбызда ике урам. Берсе аның -Гариф Ахунов, икенчесе Мөхәммәт Мәһдиев исемен йөртә. Авылга асфальт юл түшәлгән, авыл төзек, матур. Әти-әнием белән авылыбызда мин еш булам, бәйрәмнәргә кайтам, туганнарыбызның хәлләрен белешәм. Ничектер бер кайтуымда авыл урамына керүгә дәү әни: “Ә бит Гариф Ахунов белән без туганнар, ул - безнең нигездән чыккан кызның улы. Менә ичмасам, авыл халкы аның исемен мәңгеләштереп тә куйган,” – диде. Ул вакытта әле мин кечерәк идем. Шуннан соң инде уйлана башладым. Нигә мәңгеләштергәннәр? Урам исемнәре нәрсә сөйли? Ни өчен Гөберчәкнең бер урамы Гариф Ахунов исемен йөртә? Икенчесе минем өчен яхшы таныш, чөнки Мөхәммәт абый МәҺдиев - шушы авылдан чыккан язучы.

**Зөһрә** Гарипова, 9А сыйныфы

***Редактор*** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Нафиса Камалова
***Фотокорреспондент*** Зарина Халиуллина
***Корректор*** Диляра Гарифуллина
***Редколлегия*** Зиля Юсупова

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15
***Сайт школы:*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2